**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан, приостановлении действия отдельных положений Бюджетного кодекса Республики Татарстан и об установлении особенностей исполнения бюджетов бюджетной системы Республики Татарстан в 2023 году

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 декабря 2022 года

**Статья 1**

Внести в Бюджетный кодекс Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II часть), № 10 (I часть), № 12 (IV часть); 2006, № 6 (I часть), № 12 (I часть); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III часть), № 10 (I часть); 2009, № 7 – 8 (I часть), № 12 (I часть); 2010, № 7 (II часть), № 12 (I часть); 2011, № 8 (I часть), № 11 (I часть), № 11 (II часть); 2012, № 11 (I часть); 2013, № 7, № 10, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 12 (III часть); 2015, № 7 (I часть); 2016, № 3, № 6 (III часть), № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (часть I), № 76 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 78 (часть I); 2019, № 2 (часть I), № 19 (часть I), № 79 (часть I); 2020, № 51 (часть I), № 57 (часть I), № 77 (часть I), № 94 (часть I); 2021, № 20 (часть I), № 77 (часть I); 2022, № 3 (часть I), № 34 (часть I), № 49 (часть I), № 83 (часть I) следующие изменения:

1) в абзаце четвертом статьи 9 слова «указанных в пунктах 2 и 5 статьи $26^3$ Федерального закона от 6 октября 1999 года № 184-ФЗ «Об общих принципах организации законодательных (представительных) и исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации» (далее – Федеральный закон «Об общих принципах организации законодательных (представительных) и исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации»)» заменить словами «указанных в частях 1 и 5 статьи 44 Федерального

закона от 21 декабря 2021 года № 414-ФЗ «Об общих принципах организации публичной власти в субъектах Российской Федерации»;

2) в пункте 3 статьи 22 слова «и не может превышать 3 процента утвержденного указанным законом общего объема расходов» исключить;

3) в абзаце третьем пункта 1 статьи 23 слова «указанных в пунктах 2 и 5 статьи $26^3$ Федерального закона «Об общих принципах организации законодательных (представительных) и исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации» заменить словами «указанных в частях 1 и 5 статьи 44 Федерального закона от 21 декабря 2021 года № 414-ФЗ «Об общих принципах организации публичной власти в субъектах Российской Федерации»;

4) в статье 29:

а) пункт 10 изложить в следующей редакции:

«10. Размещение государственных ценных бумаг Республики Татарстан (муниципальных ценных бумаг) осуществляется Республикой Татарстан (муниципальным образованием) при отсутствии просроченной задолженности по долговым обязательствам Республики Татарстан (муниципального образования).»;

б) дополнить пунктом $10^1$ следующего содержания:

«$10^1$. В случае размещения Республикой Татарстан (муниципальным образованием) государственных ценных бумаг Республики Татарстан (муниципальных ценных бумаг) доходность к погашению, рассчитанная исходя из цены размещения указанных ценных бумаг, не может превышать ключевую ставку Центрального банка Российской Федерации, увеличенную на 1 процентный пункт, действующую на дату принятия решения о размещении государственных ценных бумаг Республики Татарстан (муниципальных ценных бумаг), если у Республики Татарстан (муниципального образования) на дату размещения отсутствует кредитный рейтинг не ниже уровня, устанавливаемого Правительством Российской Федерации, от одного или нескольких осуществляющих рейтинговые действия юридических лиц, перечень которых определяется Правительством Российской Федерации.»;

в) пункты 11 – 19 признать утратившими силу;

5) в пункте 5 статьи $29^1$ слова «с учетом положений пункта 25 статьи 103 Бюджетного кодекса Российской Федерации и пункта 16 статьи 29 настоящего Кодекса» исключить;

6) пункт 7 статьи 31 признать утратившим силу;

7) пункты 5 – 7, 9 статьи $31^1$ признать утратившими силу;

8) в пункте 3 статьи $44^4$:

а) в абзаце третьем слова «наличие в бюджете муниципального образования (сводной бюджетной росписи местного бюджета) бюджетных ассигнований на исполнение расходных обязательств муниципального образования, в целях софинансирования которых предоставляется субсидия, в объеме, необходимом для их исполнения, включая размер планируемой к предоставлению из бюджета Республики Татарстан субсидии, а также» исключить;

б) абзацы шестой и седьмой признать утратившими силу;

9) пункт 3 статьи $44^5$ признать утратившим силу;

10) в пункте 1 статьи 46 слова «Федеральным законом от 6 октября 1999 года № 184-ФЗ «Об общих принципах организации законодательных (представительных) и исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации» заменить словами «Федеральным законом от 21 декабря 2021 года № 414-ФЗ «Об общих принципах организации публичной власти в субъектах Российской Федерации»;

11) пункт 5 статьи $52^1$ признать утратившим силу;

12) абзац девятнадцатый пункта 4 статьи 61 признать утратившим силу;

13) в пункте 4 статьи 78 слова «о совершении казначейских платежей (далее – распоряжение)» исключить;

14) в статье $93^1$:

а) подпункт 2 пункта 2 изложить в следующей редакции:

«2) привлечение на единый счет бюджета Республики Татарстан и возврат привлеченных средств в соответствии с пунктами 4, 6 и 7 настоящей статьи;»;

б) пункт 5 признать утратившим силу;

в) пункт 6 изложить в следующей редакции:

«6. Министерство финансов Республики Татарстан осуществляет возврат привлеченных в соответствии с пунктом 4 настоящей статьи средств на казначейские счета, с которых они были ранее перечислены, в том числе в целях проведения операций за счет привлеченных средств, не позднее второго рабочего дня, следующего за днем приема к исполнению распоряжений получателей указанных средств.»;

г) в пункте 7 слова «пунктами 5 и» заменить словом «пунктом».

**Статья 2**

Внести в Закон Республики Татарстан от 27 сентября 2019 года № 71-ЗРТ «О внесении изменений в Бюджетный кодекс Республики Татарстан и статью 2 Закона Республики Татарстан «О внесении изменений в Бюджетный кодекс Республики Татарстан и признании утратившими силу отдельных положений актов бюджетного законодательства Республики Татарстан» (Собрание законодательства Республики Татарстан, 2019, № 79 (часть I); 2020, № 94 (часть I); 2022, № 3 (часть I) следующие изменения:

1) в пункте 22 статьи 1 слова «статьи 33 и 34 признать утратившими силу» заменить словами «статью 34 признать утратившей силу»;

2) часть $4^1$ статьи 3 признать утратившей силу.

**Статья 3**

Приостановить с 1 января 2023 года до 1 января 2024 года действие пункта 3 статьи $31^{1.2}$, пункта 3 статьи $32^1$, абзаца пятого статьи 43 (в части случаев, установленных федеральными законами) Бюджетного кодекса Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II часть), № 10 (I часть), № 12 (IV часть); 2006, № 6 (I часть), № 12 (I часть); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III часть), № 10 (I часть); 2009, № 7 – 8 (I часть), № 12 (I часть); 2010, № 7 (II часть), № 12 (I часть); 2011, № 8 (I часть), № 11 (I часть), № 11 (II часть); 2012, № 11 (I часть); 2013, № 7, № 10, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 12 (III часть); 2015, № 7 (I часть); 2016, № 3, № 6 (III часть), № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (часть I), № 76 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 78 (часть I); 2019, № 2 (часть I), № 19 (часть I), № 79 (часть I); 2020, № 51 (часть I), № 57 (часть I), № 77 (часть I), № 94 (часть I); 2021, № 20 (часть I), № 77 (часть I); 2022, № 3 (часть I), № 34 (часть I), № 49 (часть I), № 83 (часть I).

**Статья 4**

1. Установить, что до 1 января 2024 года на расходные обязательства по финансовому обеспечению мероприятий, связанных с предотвращением влияния ухудшения экономической ситуации на развитие отраслей экономики, профилактикой и устранением последствий распространения коронавирусной инфекции, а также иные расходные обязательства, определенные местной администрацией муниципального образования, не распространяются положения пункта 3 статьи 44 Бюджетного кодекса Республики Татарстан.

2. Установить, что в 2023 году дефицит бюджета Республики Татарстан (местного бюджета) может превысить размер дефицита бюджета Республики Татарстан (местного бюджета), установленный законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан (муниципальным правовым актом представительного органа муниципального образования о местном бюджете), и ограничения, установленные пунктами 2 и 3 статьи 24 Бюджетного кодекса Республики Татарстан, на сумму бюджетных ассигнований, направленных на финансовое обеспечение мероприятий, связанных с профилактикой и устранением последствий распространения коронавирусной инфекции, а также с проведением в Российской Федерации мобилизации.

3. Установить, что в 2023 году объем государственного долга Республики Татарстан (муниципального долга) может превысить установленный законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан (муниципальным правовым актом представительного органа муниципального образования о местном бюджете) верхний предел государственного долга Республики Татарстан (муниципального долга), в том числе показатели программы государственных внутренних заимствований, на сумму, не превышающую объема бюджетных ассигнований, направленных на финансовое обеспечение мероприятий, связанных с профилактикой и устранением последствий распространения коронавирусной инфекции.

4. Установить, что в ходе исполнения бюджета Республики Татарстан (местного бюджета) в 2023 году дополнительно к основаниям для внесения изменений в сводную бюджетную роспись бюджета Республики Татарстан (местного бюджета), установленным бюджетным законодательством Российской Федерации, в соответствии с решениями Кабинета Министров Республики Татарстан (местной администрации) в сводную бюджетную роспись бюджета Республики Татарстан (местного бюджета) без внесения изменений в закон Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан (муниципальный правовой акт представительного органа муниципального образования о местном бюджете) могут быть внесены изменения в случае перераспределения бюджетных ассигнований на финансовое обеспечение мероприятий, связанных с предотвращением влияния ухудшения геополитической и экономической ситуации на развитие отраслей экономики, бюджетных ассигнований на иные цели, определенные Кабинетом Министров Республики Татарстан (местной администрацией), а также в случае перераспределения бюджетных ассигнований между видами источников финансирования дефицита бюджета Республики Татарстан (местного бюджета).

5. Внесение изменений в сводную бюджетную роспись по основаниям, установленным частью 4 настоящей статьи, может осуществляться с превышением общего объема расходов, утвержденных законом Республики Татарстан о бюджете

Республики Татарстан (муниципальным правовым актом представительного органа муниципального образования о местном бюджете).

6. Установить, что по итогам исполнения бюджета Республики Татарстан (местного бюджета) в 2023 году установленный законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан (муниципальным правовым актом представительного органа муниципального образования о местном бюджете) размер дефицита бюджета Республики Татарстан (местного бюджета) может быть превышен на сумму бюджетных ассигнований, направленных на финансовое обеспечение мероприятий, связанных с предотвращением влияния ухудшения геополитической и экономической ситуации на развитие отраслей экономики.

7. Установить, что до 1 января 2024 года на средства, предоставляемые из бюджетов бюджетной системы Республики Татарстан в соответствии с решениями, предусмотренными частью 4 настоящей статьи, пунктами 3 и $3^2$ статьи 77 Бюджетного кодекса Республики Татарстан, и основаниями, предусмотренными в соответствии с пунктом $3^1$ статьи 77 Бюджетного кодекса Республики Татарстан, и на средства, зарезервированные в составе бюджетных ассигнований, утвержденных законом (решением) о соответствующем бюджете на текущий финансовый год и плановый период, не распространяются положения абзаца первого пункта 2 статьи $20^{1.3}$, пункта 2 статьи 21, абзаца пятого пункта 4 статьи $44^4$, абзаца первого пункта 4 и абзаца первого пункта $4^2$ статьи $44^5$ , пункта 10 статьи $44^6$ Бюджетного кодекса Республики Татарстан.

**Статья 5**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования, за исключением положений, для которых настоящей статьей установлены иные сроки вступления их в силу.

2. Пункты 1, 3, 10 и 13 статьи 1 настоящего Закона вступают в силу с 1 января 2023 года.

3. Положения статьи $52^1$ и пункта 4 статьи 61 Бюджетного кодекса Республики Татарстан (в редакции настоящего Закона) применяются к правоотношениям, возникающим при составлении и утверждении бюджета Республики Татарстан, начиная с бюджета Республики Татарстан на 2023 год и на плановый период 2024 и 2025 годов.

4. Положения Бюджетного кодекса Республики Татарстан при исполнении бюджетов бюджетной системы Республики Татарстан в 2023 году применяются с учетом положений Федерального закона от 21 ноября 2022 года № 448-ФЗ «О внесении изменений в Бюджетный кодекс Российской Федерации и отдельные законодательные акты Российской Федерации, приостановлении действия отдельных положений Бюджетного кодекса Российской Федерации, признании утратившими силу отдельных положений законодательных актов Российской

Федерации и об установлении особенностей исполнения бюджетов бюджетной системы Российской Федерации в 2023 году».

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
26 декабря 2022 года
№ 103-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның дүртенче абзацында «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы) $26^3$ статьясының 2 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 1 һәм 5 өлешләрендә күрсәтелгән» сүзләренә алмаштырырга;

2) 22 статьяның 3 пунктында «һәм шушы закон белән расланган чыгымнарның гомуми күләменнән 3 проценттан да артмаска тиеш» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 23 статьяның 1 пунктындагы өченче абзацында «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Татарстан Республикасы карамагындагы эшләр буенча Федераль законның $26^3$ статьясындагы 2 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән» сүзләрен «уртак карамактагы эшләр буенча «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 1 һәм 5 өлешләрендә күрсәтелгән» сүзләренә алмаштырырга;

4) 29 статьяда:

а) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Татарстан Республикасы дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен (муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне) урнаштыру Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) тарафыннан Татарстан Республикасының (муниципаль берәмлекнең) бурыч йөкләмәләре буенча кичектерелгән бурычлары булмаган очракта гамәлгә ашырыла.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $10^1$ пункт өстәргә:

«$10^1$. Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлеге) тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт кыйммәтле кәгазьләре (муниципаль кыйммәтле кәгазьләр) урнаштырылган очракта, түләп бетерү вакытына мондый кыйммәтле кәгазьләрне урнаштыру бәясеннән чыгып саналган керем Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасы дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен (муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне) урнаштыру турында карар кабул ителгән датага гамәлдә булган, 1 процент пунктка арттырылган төп ставкасыннан югарырак була алмый, моның өчен Татарстан Республикасында (муниципаль берәмлектә) урнаштыру датасына рейтинг гамәлләрендә катнаша торган, исемлекләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнүче бер яисә берничә юридик заттан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган дәрәҗәдән ким булмаган кредит рейтингы булмаска тиеш.»;

в) 11 – 19 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

5) $29^1$ статьяның 5 пунктында «, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 103 статьясындагы 25 пункты һәм әлеге Кодексның 29 статьясындагы 16 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып,» сүзләрен төшереп калдырырга;

6) 31 статьяның 7 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

7) $31^1$ статьяның 5 – 7, 9 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга;

8) $44^4$ статьяның 3 пунктында:

а) өченче абзацта «муниципаль берәмлек бюджетында (җирле бюджетның җыелма бюджет язмасында) муниципаль берәмлекнең финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә, аларның үтәлеше өчен кирәкле булган күләмдә, Татарстан Республикасы бюджетыннан бирү планлаштырыла торган субсидия күләмен дә кертеп, бюджет ассигнованиеләре булудан, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) алтынчы һәм җиденче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;

9) $44^5$ статьяның 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

10) 46 статьяның 1 пунктында «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

11) $52^1$ статьяның 5 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

12) 61 статьяның 4 пунктындагы унтугызынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

13) 78 статьяның 4 пунктында «казначылык түләүләрен башкару турында күрсәтмәләр (алга таба – күрсәтмәләр)» сүзләрен «күрсәтмәләр» сүзенә алмаштырырга;

14) $93^1$ статьяда:

а) 2 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) әлеге статьяның 4, 6 һәм 7 пунктлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетының бердәй счетына акчалар җәлеп итү һәм җәлеп ителгән акчаларны кире кайтару;»;

б) 5 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

в) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы әлеге статьяның 4 пункты нигезендә җәлеп ителгән акчаларны элегрәк алар күчерелгән, шул исәптән җәлеп ителгән акчалар исәбенә операцияләр башкару максатларында, казначылык счетларына кире кайтаруны күрсәтелгән акчаларны алучыларның күрсәтмәләрен үтәүгә кабул иткән көннән соң килә торган икенче эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашыра.»;

г) 7 пунктта «5 һәм 6 пунктлары» сүзләрен «6 пункты» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 27 сентябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 22 пунктында «33 һәм 34 статьяларны үз көчләрен югалткан дип танырга» сүзләрен «34 статьяны үз көчен югалткан дип танырга» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяның $4^1$ өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш) $31^{1.2}$ статьясындагы 3 пунктының, $32^1$ статьясындагы 3 пунктының, 43 статьясындагы бишенче абзацының (федераль законнарда билгеләнгән очракларда) гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

**4 статья**

1. Икътисадый вәзгыять начарлануның икътисад тармаклары үсешенә йогынтысын булдырмый калуга, коронавирус инфекциясе таралуны профилактикалауга һәм аннан килгән зыяннарны бетерүгә бәйле чараларны финанс белән тәэмин итү буенча чыгым йөкләмәләренә, шулай ук муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе билгеләгән башка чыгым йөкләмәләренә 2024 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясындагы 3 пункты нигезләмәләре кагылмый дип билгеләргә.

2. 2023 елда Татарстан Республикасы бюджеты (җирле бюджет) кытлыгының күләме Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы

законында (муниципаль берәмлек вәкиллекле органының җирле бюджет турындагы муниципаль хокукый актында) билгеләнгән Татарстан Республикасы бюджеты (җирле бюджет) кытлыгы күләменнән һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 24 статьясындагы 2 һәм 3 пунктларында билгеләнгән чикләүләрдән коронавирус инфекциясе таралуны профилактикалауга һәм аннан килгән зыяннарны бетерүгә, шулай ук Россия Федерациясендә мобилизация үткәрелүгә бәйле чараларны финанс белән тәэмин итү өчен җибәрелгән бюджет ассигнованиеләре суммасына артыграк булырга мөмкин дип билгеләргә.

3. 2023 елда Татарстан Республикасы дәүләт бурычының (муниципаль бурычның) күләме Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында (муниципаль берәмлек вәкиллекле органының җирле бюджет турындагы муниципаль хокукый актында) билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт бурычының (муниципаль бурычның) югары чигеннән, шул исәптән эчке дәүләт хисаплашулары программасы күрсәткечләреннән, коронавирус инфекциясе таралуны профилактикалауга һәм аннан килгән зыяннарны бетерүгә бәйле чараларны финанс белән тәэмин итү өчен җибәрелгән бюджет ассигнованиеләре күләменнән югарырак булмаган суммага артыграк булырга мөмкин дип билгеләргә.

4. 2023 елда Татарстан Республикасы бюджетын (җирле бюджетны) үтәү барышында Татарстан Республикасы бюджетының (җирле бюджетның) җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертү өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән нигезләргә өстәмә рәвештә, геосәяси һәм икътисадый вәзгыять начарлануның икътисад тармаклары үсешенә йогынтысын булдырмый калуга бәйле чараларны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (җирле администрация) тарафыннан билгеләнгән башка максатларга бюджет ассигнованиеләре яңадан бүленгән очракта, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты (җирле бюджет) кытлыгын финанслау чыганаклары төрләре арасында бюджет ассигнованиеләре яңадан бүленгән очракта, Татарстан Республикасы бюджетының (җирле бюджетның) җыелма бюджет язмасына, Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына (муниципаль берәмлек вәкиллекле органының җирле бюджет турындагы муниципаль хокукый актына) үзгәрешләр кертмичә генә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (җирле администрация) карарлары нигезендә үзгәрешләр кертелергә мөмкин дип билгеләргә.

5. Җыелма бюджет язмасына әлеге статьяның 4 өлешендә билгеләнгән нигезләр буенча үзгәрешләр кертү Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында (муниципаль берәмлек вәкиллекле органының җирле бюджет турындагы муниципаль хокукый актында) расланган чыгымнарның гомуми күләмен арттырып гамәлгә ашырылырга мөмкин дип билгеләргә.

6. Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында (муниципаль берәмлек вәкиллекле органының җирле бюджет турындагы муниципаль хокукый актында) билгеләнгән Татарстан Республикасы бюджеты (җирле бюджет) кытлыгы күләме 2023 елда Татарстан Республикасы бюджеты (җирле бюджет) үтәлеше йомгаклары буенча геосәяси һәм икътисадый вәзгыять

начарлануның икътисад тармаклары үсешенә йогынтысын булдырмый калуга бәйле чараларны финанс белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләре суммасына арттырылырга мөмкин дип билгеләргә.

7. Әлеге статьяның 4 өлешендә, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы 3 һәм $3^{2}$ пунктларында күрсәтелгән карарларга һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы $3^{1}$ пунктында каралган нигезләргә таянып, Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларыннан бирелә торган акчаларга һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына тиешле бюджет турындагы законда (карарда) расланган бюджет ассигнованиеләре составында резервланган акчаларга 2024 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $20^{1.3}$ статьясындагы 2 пунктының беренче абзацы, 21 статьясындагы 2 пункты, $44^{4}$ статьясындагы 4 пунктының бишенче абзацы, $44^{5}$ статьясындагы 4 пунктының беренче абзацы һәм $4^{2}$ пунктының беренче абзацы, $44^{6}$ статьясындагы 10 пункты нигезләмәләре кагылмый дип билгеләргә.

**5 статья**

1. Әлеге Закон, үз көченә керүнең әлеге статьяда башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1, 3, 10 һәм 13 пунктлары 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $52^{1}$ статьясы һәм 61 статьясындагы 4 пункты нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетын төзегәндә һәм раслаганда барлыкка килүче хокук мөнәсәбәтләренә 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетыннан башлап кагыла.

4. 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәгәндә Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезләмәләре «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору, Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану һәм 2023 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2022 елның 21 ноябрендәге 448-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып кулланыла.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 26 декабрь
№ 103-ТРЗ